| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.07.2024 с.Старое Дрожжаное № 296

Күп балалы гаилә статусын билгеләү турында

Россия Федерациясе Президентының «Күп балалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары турында» 2024 елның 23 гыйнварындагы 63 номерлы Указы нигезендә, социаль ярдәм чараларын күрсәтү максатларында һәм Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Күп балалы гаилә статусын билгеләү турында» 2024 елның 18 июнендәге 20-09/8480 номерлы хатына таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының мәгариф оешмаларында күп балалы гаиләләргә муниципаль хезмәтләр, ташламалар күрсәткәндә, федераль дәрәҗәдә бердәм үрнәк таныклык билгеләнгәнче, балаларның тууы турында таныклык яки Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә статусын билгеләү (күпбалалы гаилә таныклыгын бирү, аны озайту һәм алмаштыру) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын билгеләү турында» 2012 елның 31 июлендәге 612 номерлы боерыгы белән расланган Күп балалы гаилә статусын билгеләү турында карар нигезендә ташламалар һәм хезмәтләр күрсәтергә.

2. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән законлы көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары А.Ф. Җәләловка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.И. Мөхәммәтҗанов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОГРН 1061672000609 ИНН 1617003116